**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

2020елның 8 сентябре 60 -РС номер

# КАРАР

## «Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына аренда түләүләрен түләүне кичектереп тору өлешендә ярдәм чаралары турында» 2020елның 20 маендагы 24-РС номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 19 мартындагы 670-р номерлы «Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм чаралары турында» күрсәтмәсе белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020елның 22 апрелендәге № 820-р күрсәтмәсе белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.04.2020 № 820-р күрсәтмәсенә үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 14 августындагы 1536-р номерлы күрсәтмәсе белән, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карар чыгарды:

1. «Аренда түләүләрен түләүне кичектереп тору өлешендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм чаралары турында» 2020елның 20 маендагы 24-РС номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1 пунктта:

«а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) 2020 елның 1 апреленнән 2020 елның 1 октябренә кадәр аренда түләүләрен түләүне кичектерүне күздә тоткан Татарстан Республикасы дәүләт казнасын (шул исәптән җир кишәрлекләрен) тәшкил итүче дәүләт мөлкәтен арендалау шартнамәләре буенча, кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән арендаторлар - кече һәм урта эшкуарлык субъектлары, Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар - коммерциячел булмаган оешмалар реестрына кертелгән иҗтимагый файдалы хезмәтләр башкаручылар мөрәҗәгать иткән көннән алып җиде эш көне дәвамында, өстәмә килешүләр төзү түбәндәге шартларда:

аренда түләве буенча бурыч 2021 елның 1 гыйнварыннан да иртәрәк түләнергә тиеш түгел, әмма 2023 елның 1 гыйнварыннан да соңга калмыйча,

этаплап, айга бер тапкырдан да артмыйча, аренда килешүе буенча айлык аренда түләве күләме яртысыннан артмый торган түләүләр белән түләнергә тиеш;

кичектерүгә бәйле рәвештә, арендатор тарафыннан аренда түләвен кертү тәртибен һәм срокларын сакламау (шул исәптән мондый чаралар аренда килешүендә каралган очракларда) белән бәйле рәвештә, чит акчалардан файдаланган өчен штрафлар, процентлар яки башка җаваплылык чаралары кулланылмый;

кичектереп тору белән бәйле рәвештә арендатор тарафыннан түләнергә тиешле өстәмә түләүләрне билгеләү рөхсәт ителми;

аренда килешүен вакытыннан алда өзгәндә аренда түләве буенча бурыч бер үк вакытта түләнә;»;

«б» пунктчасында «кече һәм урта эшкуарлык субъектлары "сүзләреннән соң « социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар турында" сүзләрен өстәргә»;

2 пунктта:

"а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы кертелгән датага аларның Татарстан Республикасы дәүләт казнасын (шул исәптән җир кишәрлекләрен) тәшкил итүче дәүләт мөлкәтен арендалау шартнамәләре буенча узган чор өчен аренда түләүләрен түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмаган арендаторларга- кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга - коммерциячел булмаган оешмалар реестрына кертелгән иҗтимагый файдалы хезмәтләр башкаручыларга аренда түләүләрен түләүне кичектерү бирелә дип билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына әлеге карарның үтәлеше турында Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына 2020 елның II кварталыннан башлап, кварталдан соң килүче айның 10 числосыннан да соңга калмыйча мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм интернет-телекоммуникация челтәрендәге Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы**
**башлыгы-Совет рәисе**
**вазыйфаларын башкаручы** **Т.П.Борһанова**